ТАТАРСТАН ВАРИСЛАРЫ

# Җиде энҗе бөртеге





УДК 821.512.145
ББК 84(2=632.3)6
Җ 38

ISBN 978-5-6043753-0-3

©Татарское Детское Издательство

ТОИ ЭМОЦИОНАЛЬНЫЙ ИНТЕЛЛЕКТ
ТАТАРСКОЕ ДЕТСКОЕ ИЗДАТЕЛЬСТВО • ТАТАР БАЛАЛАР НӘШРИЯТЫ

Татарстан тарихы һәм мәдәнияте
мавыктыргыч формада

# Җиде энҗе бөртеге

КАЗАН
2021

Монда татар әкиятләре яши

tatbook.ru



## КАДЕРЛЕ ДУСТЫМ!

Бу китап сиңа маҗаралар яратучы, туган якның тарихын яхшы белүче Роман һәм Зөләйха белән бергә мавыктыргыч сәяхәттә катнашу мөмкинлеге бирә. «Мирас Угы» анимацион сериалында алар дөньяны явызлыктан коткардылар инде. Беренче маҗаралардан соң озакламый безнең кызыксынучан геройлар яңадан юлга чыга. Бу хәлләрнең ничек беткәнен сиңа «Җиде энҗе бөртеге» дигән китап сөйләп бирер.


МИРАС УГЫ
АНИМАЦИОН ФИЛЬМ
www.стреланаследия.рф

# КЕРЕШ СҮЗ

Бервакыт аерылмас дуслар Зөләйха белән Роман музейга кереп чыгарга булдылар. «Әйдә, Йорт иясе белән күрешеп чыгыйк әле, – дип тәкъдим итте Роман үзенең дустына. – Ничек яшәп ята икән ул анда?» Бер дә гаҗәпләнмәгез, безнең геройларыбыз чып-чын Йорт иясе белән дус. Бервакыт Йорт иясе аларга буталчык тарихи маҗаралар вакытында булышкан иде. Хәзер ул музейда борынгы хәзинәләрне саклаучы булып эшли.

Йорт иясе дусларын музейга кергәндә үк шатланып каршы алды: «Миңа бик мөһим эш тапшырдылар: безнең халыкка хас сыйфатларны күрсәтә торган җиде символ табарга кирәк. Мин тәмам буталып беттем, сезнең ярдәмнән башка булмый монда!» – дип, дусларыннан булышуларын үтенде ул.







# ТӘМЛЕ-ТАТЛЫ СЕРЛӘР

Беренче бүлектә Йорт иясе дусларын табынга чакыра, ә Роман кунакчыллыкның серенә төшенә.


КАССА



Дуслар, мин сезнең ярдәмегезгә бик тә өметләнәм! Әйдәгез, иң элек табынга рәхим итегез әле.

Түр якта Зөләйха белән Романны өстәл тулы сый көтә иде.

– Бирегә кунакларны милли чәй табыны гадәтләре белән таныштыралар, – дип дәвам итте сүзен Йорт иясе. – Миңа бер сорау тынгылык бирми. Сез ничек уйлыйсыз: татарларның кунакчыллыгы символы нәрсә икән?






Татарларның килгән кунакны иң элек табынга чакыруларын Роман белә иде инде, шуңа күрә дә үзләре өчен әзерләнгән табынны күргәч, ул гаҗәпләнмәде. Өстәл уртасында самавыр җырлап утыра, аның тирәсенә кыстыбый, бәлеш, гөбәдия, татлы катлама һәм башка бик күп тәм-томнар куелган. Тик киң күңеллелекнең символы нәрсә булуына Роман әлегә төшенмәде.



Як-ягына карангалап утыра торгач, Роман акшарланган матур мичне күреп алды. «Бу тәмле ризыкларны шушы мичтә пешереп була икән бит», – дип уйлап куйды ул һәм мичне җентекләп өйрәнә башлады. Бу Роман белгән башка мичләрдән нәрсәсе беләндер аерылып тора... «Әһә, моның казан куела торган махсус урыны бар икән», – дип аңлап алды ул.



Роман, син ничек уйлыйсың, безнең борынгы әби-бабайлар ризыкны кайда пешергәннәр?

– Учакта.

– Дөп-дөрес. Безнең борынгы бабалар күченеп йөргән далаларда утын күп булганмы соң?

– Юк, дип уйлыйм.

– Дөрес уйлыйсың. Алар, учак җылысы әрәм булмасын өчен, тиз җылына һәм әкрен суына торган савыт уйлап тапканнар. Шуңа күрә ризык учакта тиз пешкән. Казан – әнә шул күптән узган вакытлар ядкаре.



Роман шуны аңлады: мич һәм казан. Менә нәрсәдә икән ул ризыкларның искиткеч тәмле булып пешүенең сере. Татарларга хас кунакчыллыкның символы да нәкъ менә шулар инде.







# КҮҢЕЛГӘ ЯТЫШЛЫ АҺӘҢНӘР

Икенче бүлектә Роман белән Зөләйха музыка тыңлыйлар һәм барлык уен коралларының да күңелгә бер үк төсле тәэсир итмәгәнен абайлыйлар.



Ә хәзер мин сезгә музыка уен коралларын күрсәтәм, – диде Йорт иясе. – Бу бүлмәдә бик күп төрләре бар аларның. Тик мин аларның кайсысыннан чыккан көй татар халкының күңеленә хуш килгәнен һәм хис-кичерешләрен ачып бирә алганын белмим.

– Нәрсә соң ул күңелгә хуш килү, хис-кичерешләрне ачу? – дип кызыксынды Роман.

– Музыка тыңлаганда, син борынгы бабаларың хисләрен кичергәндәй буласың, – дип, Йорт иясе урынына сөйләп китте Зөләйха.







Ничек алай була соң ул? Уен коралында уйнауның аерым бер алымы бармы әллә? – дип, аптыраашта калды Роман.






– Ю-у-ук, Роман. Халык көйләре нота һәм сүзләрдән генә тормый, алар үзләрендә бу җирләрдә элек яшәгән халыкларның эчке халәтләрен дә саклыйлар, – дип аңлатып бирде Зөләйха. – Милли көйләрдә без әби-бабаларыбызның уй-хисләрен тоябыз. Алар куанганда – җырлаган-биегән, борчылганда – моңланган. Моң – ул ихлас күңелдән көйләү.




МОҢ



Үен коралларының кайсысы моңлырак икәнен белү өчен, аларда уйнап карарга кирәк, – дип тәкъдим кертте Роман.

– Йорт иясе рөхсәт итсә, уйнап карарбыз. Синең сорамыйча шөлдергә ук атканың әле дә исемдә, – диде Зөләйха.

Роман бер-бер артлы саксофонда, гитарада, быргыда, балалайкада уйный башлады. Тик эзләгән аһәң табылмады: алар йә песи баласы кебек мияуладылар, йә арыслан шикелле ырладылар.



Исемә төште, – диде ниһаять Роман. – Бервакыт без бабам белән болында йөргәндә, ул миңа чатыр чәчәкле үлән күрсәтте. Һәм ул миңа шушы үләннең куыш сабагы озын һәм матур аваз чыгара дип сөйләгән иде. Бәлки, шуны эзләп карарбыз?

Йорт иясе, куанып, музейда агачтан эшләнгән курай барлыгын исенә төшерде һәм аны Романга алып килеп бирде.



**Менә кайда ул Моң, – дип елмайды Зөләйха, дустының уйнаганын тыңлап. – Татарның күңелләргә үтеп керә торган җыр-моң символы менә шушы курай икән бит.**









# БОРЫНГЫ ӘБИ-БАБАЙЛАР СӘЛАМЕ


Өченче бүлектә Роман белән Зөләйха сорауга җавап эзлиләр һәм тәңкә табалар.

Йорт иясе, Роман һәм Зөләйха акча сугу кораллары һәм иске акчалар саклангaн урынга керәләр.

– Бик борынгы бабаларыбызның күчмә тормыш алып барулары сер түгел. Барысы да түгел, әлбәттә, шулай да күпчелеге. Сәяхәт итәргә ярату, яңа җирләр ачарга хыяллану, танышырга һәм аралашырга омтылу, яңарышка йөз тоту – боларның һәммәсе дә хәзерге заман кешесенең күңелендә яшәвен дәвам итә. Милли символларның берсе шушыларга бәйле, дип ышанып әйтә алам. Тик нәрсә икәнен генә белмим, – диде Йорт иясе.







Безнең борынгы бабаларыбызның сәяхәтчеләр һәм яхшы сәүдәгәрләр булуы очраклылык түгел, – дип хуплады Зөләйха. – Якында гына Идел, Кама елгалары ага. Кәрван юллары биредән үткән. Кешеләр монда һәр тарафтан килгәннәр! Вакытлар узу белән, безнең төбәк зур сәүдә үзәгенә әверелгән. Көнчыгыш һәм Көнбатыш тарафлардан килгән кәрваннар биредә – безнең җирдә очрашканнар.





Димәк, бирегә бик күп илләрдән тәңкә акчалар алып килгәннәр һәм күптөрле товарлар алып киткәннәр.

Роман музей киштәләрендәге тәңкәләрне бик кызыксынып карады. Ул аларда – арыслан, зилант, кояш, ай, ә кайберләрендә язулар күрде.

– Яхшы теләкләр, – дип аңлатты аларны Зөләйха.

Бүлмәнең бер почмагында акча сугу җайланмасы тора иде.

– Мин дә акча сугып карыйм әле, – дип, Роман чүкеч белән бар көченә сандалга сукты.







Роман! – дип кычкырып, Зөләйха дусты янына йөгереп килде дә нотык сөйләргә тотынды. – Бу бит саксофон да, гитара да түгел! Тагын берәр нәрсәне ватсаң яисә явызлыкны ирекка чыгарсаң?! Йорт иясе сиңа бүлмәдәге экспонатларга тиярга рөхсәт итмәде бит. Син аларның бик борынгы икәннәрен белмисеңме әллә?

Йорт иясе, чүкеч астыннан сикереп чыккан тәңкәгә карап, Зөләйханы туктатты.

– Зөләйха, орышма Романны. Ул минем башым җитмәгән табышмакны чиште бугай. Бу бит борынгы тәңкә!

**Тәңкә – безнең яклардагы үзара татулык, милләтләр дуслыгы символы, – дип, шатланып кычкырды Роман һәм, аны бармаклары белән әйләндергәләгәч, кесәсенә салып куйды.**







# ЧӘЧӘКЛЕ БИЗӘК

Дүртенче бүлектә Роман белән Зөләйха хәзинә сакланган урынга килеп эләгәләр һәм борынгы бизәкләр серен чишәләр.

Дуслар, Йорт иясенә ияреп, хәзинәләр саклanган урынга килеп керделәр.

– Кайдадыр шушында табигатькә мәхәббәт символы яшеренгән, тик мин аны кайдан эзләргә икәнен белмим, – дип, борчылуын белдерде Йорт иясе.

Дуслар биредә борынгы кием-салымнарга, кулдан сугып эшләнгән чигүле япмаларга, тастымал һәм мендәр тышларына һәм тагын башка шундый матур бизәкле нәрсәләргә тап булдылар. Бермәлгә Роман үзен чәчәкләр үсеп утырган бакчага килеп кергәндәй хис итте: тукымалардагы чигешләр шулкадәр матур иде.







Чигү үрнәкләре итеп чәчәкләрне сайлаганнар, – дип аңлатты Зөләйха. – Кашкарый, кыңгырау чәчәк, күкчәчәк, ә соңрак – лилия, лалә. Кызлар нинди чәчәк күрсәләр, кайсысына соклансалар, ошатсалар, шуны тукымага төшергәннәр. Тагын да матуррак булсын өчен, оста куллар махсус ефәк, алтын, көмеш җепләр белән чиккәннәр һәм тукыма читләрен тамбур белән челтәрләп бизәгәннәр.





Бизәкләрне сокланып караудан тыш, әле «укып» та буламыни? – дип сорап куйды Роман.

– Әйе. Бизәкләрдәге түгәрәк – кояш, шакмак – җир, дулкынлы сызыклар – су, агач һәм кошлар уңдырышлылык билгесе булып тора.

– Кирәк бит, – дип куйды Роман. – Димәк, бу әйберләрдә ниндидер код яшеренгән. Нәрсә икән соң ул?



Роман бер матур сөлгене кулына алды. Берничә секунд аның бизәкләренә карап торганнан соң, тирән сулыш алып:

– Безнең төбәкнең табигате шундый матур дип уйламаган идем мин, – диде.



Кул белән чигү – менә нәрсә икән ул табигатькә мәхәббәт символы.




40



# БӘЙРӘМДӘ ДӘ, ХЕЗМӘТТӘ ДӘ

Бишенче бүлектә дуслар сабырлык һәм тырышлыкның асылына төшенәләр.



Безнең төбәктә сәүдә белән һөнәрчелек кенә түгел, игенчелек тә киң таралган була, – дип сөйләп китте Йорт иясе. – Крәстиян ел буе җир эшкәрткән, иген иккән һәм урып-җыйган. Безнең якташлар беркайчан да эшсез утырмаган һәм бик тырыш булган. Әйдәгез, мин сезне остаханәгә алып барам, безнең борынгы бабаларыбызның хуҗалык итәр өчен күпме көч куйганнарын, нәрсәләр ясаганнарын күрерсез. Тырышлыкның символы нәрсә булуын да ачыкларбыз.





Остаханәдәге махсус киштәләрдә вакытлар узу белән төсләрен җуйган чалгы, урак, ашлык бөртекләрен он итеп тарттырыр өчен тегермән ташлары, орлыклар саклана торган зур чүлмәкләр урнашкан. Аерым бер урында ат дагалары һәм ат җигү өчен кирәкле дирбияләр тора. Иген кырын аттан башка күз алдына да китереп булмый бит. Җигелгән ат белән сабанны да тартканнар, игенне әвенгә дә ташыганнар.








14



Кырда эш башланган һәм тәмамланган вакытларда халык бәйрәм иткән, – дип сөйли башлады Зөләйха. – Иген чәчү, печән чабу, ашлык уру кебек кыр эшләрен башлауны һәм тәмамлауны билгеләп үткәннәр.

– Мин шундый бәйрәмнәрнең кайберләрен беләм, – дип өстәп куйды Роман. – Бу Сөмбелә, Җыен яки Сабантуй. Сабантуй ат чабышыннан башка узмый. Безнең борынгы бабаларыбыз эш вакытында да, бәйрәмнәрдә дә аттан аерылмаганнар.





Роман экспонатларны карый-карый мавыгып китте, дусларыннан артка калганын сизмәде дә. Зөләйханың сүзләре дә ерагайды, кинәт ул сискәнеп китте: «Ат дигәндә, чабыш һәм бәйрәмнәр түгел, ә сабан күз алдына килә түгелме соң?! Без татар халкының тырышлыгы кебек иң зур экспонат турында оныта язганбыз бит!»

Ул бу ачышы турында дусларына сөйләде, ә Йорт иясе шатланып аның аркасыннан сөйде.



**Сабан – хезмәт сөючәнлек символы, – диде Зөләйха. Ә менә күп гасырлар буена тупланган тәҗрибә һәм сабырлык, һичшиксез, уңыш китерә.**





# ИМИНЛЕК УКЧЫСЫ

Алтынчы бүлектә Роман төз атып кыл уртага тидерә һәм укның сихерен кире кайтара.

Дуслар, моның белән генә бетмәде әле, – диде Йорт иясе. – Безне бер авыр эш көтеп тора.

Роман ишегалдына карады һәмерактарак мишень, төгәлрәге, ал тасмага асып куелган кыршау күрде. Аннан ерак түгел генә ук белән җәя ята иде.







Беләсеңме, – дип дәвам итте Йорт иясе, – безнең борынгы бабаларыбызга  еш кына корал белән эш итәргә туры килгән. Тыныч вакытта алар ауга чыкканнар, үзләренә азык, кием өчен тире хәстәрләгәннәр. Сугыш чыкса, дошман явыннан сакланганнар. Сугышчыларның кылычлары, ук һәм җәяләре, сөңгеләре булган һәм, әлбәттә, сугыш балтасы киң таралган корал саналган, чөнки аны бар кеше дә куллана белгән. Тик чын сугышчы уктан төз ата белергә тиеш булган.



Күптән түгел мин бер явыз сугышчының коралын таптым. Риваятьләрдән билгеле булганча, җәя иясенең явызлыгын гасырлар узгач та үзендә саклый икән. Ә безнең монда, аңлавыгызча, музей...

Бәхеткә, аннан бу явыз көчне чыгарып була, моның өчен кыю егет уктан төз атарга тиеш. Уйлавымча, бу эшкә нәкъ менә син туры киләсең. Ничек, атасыңмы?

– Әлбәттә, – дип, уйлап та тормастан җавап бирде Роман.

Ул тиз генә җәяне кулына алды да укны мишеньгә төбәде.






Бер... ике... өч... – Роман бермәлгә тынып калды һәм җәя керешен ычкындырып җибәрде. Ук кыршауның нәкъ уртасыннан үтте.

– Булдырдың, – дип, шатланып, кулларын чәбәкләде Зөләйха.



Үк һәм җәя – чын батырларга хас кыюлык һәм җитезлекнең символы менә шулар икән.




2+2=4
8+7=15
Тема:
История
Татарстана




# ГЫЙЛЕМ ХӘЗИНӘСЕ


Җиденче бүлектә дуслар китапханәгә баралар һәм тарихка эләгәләр.



Хәзер китапханәгә сугылып чыгарбыз, – диде Йорт иясе. – Анда да ачыклыйсы нәрсәләр бар әле.

Китапханәгә кергәч, Роман белән Зөләйха башларын күтәреп өскә карадылар, биек китап киштәләре түшәмгә үк тиеп торалар. Тонык кына яктыртылган озын-озын киштәләр борынгы лабиринтны хәтерләтәләр иде. Йорт иясе каяндыр алдан ук әзерләп куелган китапны алды.





Китап бик борынгы һәм үзенчәлекле иде. Күн тышлы һәм бераз тузанланган. Күрәсең, бер генә гасыр сакланмыйдыр.

– Мин аны күптән түгел генә таптым һәм бер нәрсәне аңлый алмыйм: ни өчендер бу кулъязма китап уртасына кадәр генә язылган. Мондый кулъязма китапларны махсус перчатка киеп кенә тотарга ярый. Әйдәгез, өстәл янына килик, – диде Йорт иясе.



Зөләйха белән Роман, ап-ак перчатка киеп, саклык белән генә китапның таушалган битләрен ачтылар. Һәм аның беренче битеннән үк борынгы бабалары яшәгән чорны күрделәр. Алар бер-бер артлы күчмә халыклар тормышы, борынгы дәүләтләр һәм гүзәл шәһәрләр белән таныштылар. Китап гаҗәеп мавыктыргыч иде, тик иң кызыклы җирендә тукталды.





Әнишләп дәвамы юк? – дип сорады Роман, кәефе китеп.

– Чөнки шуннан соң тарих үзе юк әле, – дип җавап бирде Зөләйха, тиз генә аңлап алып. – Безгә гасырлардан килгән гыйлем ачылды, тик халкыбызның алдагы язмышы әле билгеле түгел. Аның нинди булуы үзебездән, безнең кебек үк малай-кызлардан тора. Без ничек укырбыз, бабаларыбыздан калган белемне дөрес кулланырбызмы? Иң мөһиме – үз тарихыбызны без үзебез язачакбыз.



Китап – гасырлар аша килеп ирешкән гыйлем, зирәклек символы.



Искиткеч, – диде Йорт иясе, кул чабып, һәм Роман белән Зөләйхага рәхмәтен белдерде. – Сез миңа күп нәрсәнең серен ачарга булышып кына калмыйча, халкыбызга хас булган сыйфатларны билгеләүче җиде символны да ачыкладыгыз. Мин сезгә башта әйтмәгән идем, әгәр сез, символларны бергә туплап, үзегезгә билгеле җиде сүзне әйтсәгез, алар борынгы бабаларның куәтен һәм көчен туплаган энҗе муенсага әверелер. Ул музейда торыр, кешеләр аны күреп шатланырлар, ә мин аны күз карасыдай саклармын.



# ЭЧТӘЛЕК

Тәмле-татлы серләр ........................................................................9

Күңелгә ятышлы аһәңнәр ..............................................................19

Борынгы әби-бабайлар сәламе .....................................................29

Чәчәкле бизәк .................................................................................39

Бәйрәмдә дә, хезмәттә дә .............................................................49

Иминлек укчысы .............................................................................59

Гыйлем хәзинәсе .............................................................................69

# Җиде энҗе бөртеге

## 3-е издание

Руководитель проекта
**Азат Ганиев**

Художественный руководитель
**Дмитрий Гиацинтов**

Авторы:
**Ирма Ишмуратова, Ильнур Кулдубаев**

Литературная редакция:
**Румия Юналеева, Гюльнара Фазлиахметова, Ольга Афанасьева, Фансия Сафина, Инна Макарова, Алсу Низамеева, Гульнара Головина, Гузель Нежметдинова, Фарида Ахметзянова, Зухра Фасхиева**

Художники-иллюстраторы:
**Александра Ахтямзанова, Дарья Митрофанова, Аида Ромашова, Наталья Кочергина, Татьяна Винникова, Ленар Нуриев, Гузель Гилазетдинова, Миляуша Нигмедзянова**

Руководитель IT отдела
**Дамир Бариев**

Разработчик приложения на Unity **Антон Жилнов**
3D моделлер и аниматор **Айнур Камальтдинов**

Технический директор
**Ильдар Низаметдинов**

Методисты:
**Эльмира Тахавиева, Лейсан Зинатуллина, Татьяна Курамшина**

Консультанты:
доктор исторических наук **Г. Р. Назипова**
кандидат педагогических наук **Р. Р. Шамсутдинова**

Куратор проекта
**Лейла Фазлеева**

Татарское детское издательство
420124, г. Казань, ул. Сулеймановой, 5.
www.tdpress.ru

Подписано в печать 15.01.2021.
Печать офсетная. Тираж 2000 экз. Заказ №
Отпечатано в полном соответствии с качеством предоставленных
Татарским детским издательством материалов в типографии филиала
АО «ТАТМЕДИА» «ПИК «Идель-Пресс».
420066, г. Казань, ул. Декабристов, 2.

ТАТАРСТАН ВАРИСЛАРЫ

ТДИ ЭМОЦИОНАЛЬНЫЙ ИНТЕЛЛЕКТ
ТАТАРСКОЕ ДЕТСКОЕ ИЗДАТЕЛЬСТВО • ТАТАР БАЛАЛАР НӘШРИЯТЫ

www.семьжемчужин.рф

ISBN 978-5-6043753-0-3
9 785604 375303

© Татарское Детское Издательство
www.tdpress.ru